Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 24 июнендәге 122 номерлы “Татарстан Республикасы Апас муниципаль районында ирекле (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашучыларга ярдәм чаралары исемлеген раслау турында” карары

"Хәйрия эшчәнлеге һәм иреклелек (волонтерлык) турында" 1995 елның 11 августындагы 135-ФЗ номерлы Федераль законның 17.4 статьясындагы 3 пункты нигезендә, "иреклелек (волонтерлык) өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында һәм аерым мәсьәләләргә үзгәрешләр кертү хакында" 2018 елның 30 июнендәге 48-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 4 өлешенең 2.3 пунктын үтәү өчен "Татарстан Республикасы закон актлары" һәм, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «ирекле (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашучыларга ярдәм чаралары исемлеген раслау турында " 2024 елның 3 декабрендәге 1092 номерлы карарына таянып, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районында ирекле (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашучыларга ярдәм чараларының кушымтада бирелә торган исемлеген расларга.

2."ДОБРО.РФ"иреклелек (волонтерлык) үсеше өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасында гамәлгә ашырыла торган ярдәм чаралары турында мәгълүматны үз вакытында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Б.Н. Әхмәтҗанов

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 24 июнендәге 122 номерлы карары белән расланды

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районында ирекле (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашучыларга ярдәм чаралары исемлеге

| N<br>п/п | Ярдәм чаралары | Ярдәм чаралары өчен җаваплы |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Финанс ярдәме | | |
| 1 | Татарстан Республикасының ирекле (волонтерлык) бергәлеге тарафыннан семинарлар үткәрү | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге |
| 2 | Иреклеләрнең (волонтерларның)шәхси кенәгәләрен | «Алга»яшүсмерләр клубы |

| | | |
|---|---|---|
| | рәсмиләштерү | |
| 3 | Ирекле (волонтерлык) оешмалар чараларын оештыру һәм үткәрү өчен биналар (мәйданчыклар) бирү | Апас муниципаль районы башкарма комитеты |
| 4 | Ирекleләрнең (волонтерларның) җәмәгать эшлеклеләре белән тематик очрашуларын оештыру | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге, «Алга " яшүсмерләр клубы |
| 5 | Ирекле (волонтерлык) хәрәкәте вәкилләренең, шул исәптән "көмеш" волонтерларның (55 яшьтән өлкәнрәк гражданнар) форумнарда, слетларда, семинарларда, конференцияләрдә, мастер-классларда катнашуында ярдәм күрсәтү | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге, «Алга " яшүсмерләр клубы |
| 6 | Ирекле (волонтерлык) чаралары өчен дизайн-макетлар эшләү | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге, «Алга " яшүсмерләр клубы |
| Мәгълүмати ярдәм | | |
| 7 | Тармак компетенциясе буенча ирекле (волонтерлык) эшчәнлек өлкәсендәге гамәлләр турында "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми ресурсларда мәгълүмат урнаштыру | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге, «Алга "яшүсмерләр клубы, «Татмедиа» АҖнең «Апас-Информ" филиалы (килешү буенча) |
| 8 | Ирекле (волонтерлык) эшчәнлеген яктыртуга массакүләм мәгълүмат чараларын җәлеп итү | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге, «Апас-Информ» «Татмедиа " АҖ илиалы (килешү буенча) |
| Консультация ярдәме | | |
| 9 | Ирекле (волонтерлык) эшчәнлеген оештыру, ирекле (волонтерлык) эшчәнлеге өлкәсендәге конкурсларда катнашу мәсьәләләре буенча консультацияләр үткәрү | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге, «Алга " яшүсмерләр клубы |
| Мөлкәти ярдәм | | |
| 10 | Биналарны түләүсез файдалануга бирү | Апас муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы |